2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2023 елның 22 ноябере № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында гражданнар җыены **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1. 2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Песәй авылы җирлегенең Песәй авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, карамагында балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия армиясенә хәрби хезмәткә чакырылганнардан 500 сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларын, төзәтү колонияләрендә җәза үтүчеләрне түләүдән азат итәргә

2. Үзара салымның алынган акчаларын түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- юлларны кардан чистарту;
- вак таш сатып алу;
- вак ташны тигезләү;
- мәктәп территориясе периметры буенча койма тоту;
- Яшьләр һәм Тукай урамына видео күзәтү камералары урнаштыру;
- мәктәп территориясендә биек агачларны кисү;
- санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү буенча хезмәтләр;
- авыл җирлеге исеме белән Стелла урнаштыру;
- Сабантуй бәйрәмен үткәрү мәйданчыгында сәхнә кую:
- гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту ( үлән чабу);
- узган еллардагы калган калдыкларны юлларны чистартуга җибәрү.».

3. Әлеге карарны Песәй авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatar.ru "Песәй авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Песәй авыл җирлеге башлыгы В.И. Мөхәммәтгалиев